ГЛАВА КАРАКАШЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Сирина Батыршина, д.33,
с.Каракашлы, 423961

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КӘРӘКӘШЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Сирин Батыршин урамы, 33 йорт,
Кәрәкәшле авылы, 423961

Тел.:(85593) 4-21-34, факс:4-21-21, e-mail: Karak.Utz@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01.12.2021 ел № 5

2022 елда Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлегендәге Ак-Чишмә торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы карары, Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Кәрәкәшле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 14 маддәсе нигезендә, Ютазы муниципаль районы «Кәрәкәшле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы КАРАР ИТТЕ:

1. 2021 елның 15 декабренә 14.00 сәгатьтә Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге Ак Чишмә торак пунктында Татарстан Республикасы, Ютазы районы, Ак Чишмә авылы, Ак Чишмә ур., 12 йорт адресы буенча урнашкан йорт янында 2022 елда үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«2022 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге Ак Чишмә торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, балигъ булган һәр кешедән 400 (дүрт йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

-Ак Чишмә торак пунктында авыл эчендәге юлларны карап тоту ( юлларны кардан чистарту, килешү нигезендә эшләр өчен түләү);

-Ак Чишмә торак пунктында янгын гидрантлары сатып алу һәм урнаштыру (килешү нигезендә эшләр өчен түләү).

«ӘЙЕ» «ЮК».

3. Әлеге карарны Кәрәкәшле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында кабул ителгән көннән 5 көн эчендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән (халыкка җиткерелгән көннән) үз көченә керә.

Ютазы муниципаль районы
Кәрәкәшле авыл җирлеге башлыгы А.Г.Дәүләтгәрәев